# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын Чишмә торак пунктында
2022 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**15.12.2021 ел** **№ 4**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципал районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын Чишмә торак пунктында халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Салкын Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Салкын Чишмә торак пункты, Чапаев урамында су юлы челтәрен ремонтлау ( материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Салкын Чишмә авылы Чапаев урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, ремотнлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, алып кайту, төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Салкын Чишмә торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан арындыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

Җыенда рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев